**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 23 июнь № 431

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләрен билгеләү, алар белән хезмәт шартнамәләре төзү, аларны аттестацияләү тәртибе турында» 2009 ел, 16 июль, 496 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләрен билгеләү, алар белән хезмәт шартнамәләре төзү, аларны аттестацияләү тәртибе турында» 2009 ел, 16 июль, 496 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 31 декабрь, 922 нче; 2010 ел, 10 сентябрь, 725 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 820 нче; 2013 ел, 13 декабрь, 982 нче; 2015 ел, 12 март, 148 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре белән төзелгән хезмәт шартнамәләрен Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләренең хезмәт шартнамәләре реестрында теркәүне тәэмин итәргә, хезмәт шартнамәләрен төзү буенча вәкаләтләр Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләреннән тыш. Хезмәт шартнамәләрен төзү буенча вәкаләтләр Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең бүтән органнарына тапшырылган Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләре белән хезмәт шартнамәләрен теркәүне башкарма хакимиятнең күрсәтелгән органнары гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков